ЭШЛӘП ЯШӘҮ

Саба районының Сатыш авылыннан Садыйковларның тормыш кагыйдәләре

> 2

НУРЛЫ ЙОРТ

Гаиләдә кыз баланы кем һәм ничек тәрбияләргә тиеш?

> 3

КИЛӘСЕ ЕЛГА

«Ак барс» Гагарин Кубогын ота алмады

> 6

МАРАТ КӘБИРОВ:

«Данлыклы кешеләр күп авылда, ә тишек берәү генә...»

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 62 (29029) | Чәршәмбе | 3 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ТЫНЫЧЛЫК ХАКЫ

Бәйрәм алдыннан

Яшь аралаш елмаеп бәйрәм итә торган Җиңү көне якынлаша. Сафлары елдан-ел сирәгәя барган ветераннарыбызны тагын да кадерли, җиңү һәм тынычлык хакы турында кабат уйландыра торган көн бу. 9 Май көнне республикада күпсанлы бәйрәм чаралары узачак. Башка еллардан аермалы буларак, быел ветераннарны махсус хәрби операциядә катнашкан егетләр дә котлаячак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Тарих бозылмасын

Бөек Ватан сугышында Татарстаннан 700 меңнән артык каһарман катнашкан. Шуларның яртысы гына кире әйләнеп кайткан. Бүген республикада барлыгы 14277 Бөек Ватан сугышы ветераны яши. Татарстан хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова сүзләренә караганда, соңгы биш елда аларның сафы өч тапкыр сирәгәйгән (таблицада. – **Д.Г.**)

– Республикада яшәүче барлык ветераннарга социаль ярдәм чаралары күрсәтелә. Аерым алганда, Бөек Ватан сугышы ветераннарына торак-коммуналь хезмәтләр, җәмәгать транспортында йөргән өчен түләгәндә 50 процент ташлама ясала, протезлар белән тәэмин ителә, аларга ай саен акчалата компенсация түләнә. Тыл ветераннары исә айлык түләүдән (2023 елда – 867 сум. – **Ред.**) тыш, теш һәм колак протезлары белән бушлай тәэмин ителә, – ди министр.

Шулай да, тынычлык бүләк иткән каһарманнарыбыз барыннан да бигрәк игътибарга, кадер-хөрмәткә мохтаҗ. Бәйрәм якынлашкан көннәрдә бигрәк тә. Бөек Җиңүнең 78 еллыгы уңаеннан уздырылган бәйрәм чаралары да иң беренче чиратта әнә шул максатны күздә тота. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева сүзләренә караганда, башка еллардан аермалы буларак, быел ветераннарны махсус хәрби операциядә катнашкан егетләр дә котлаячак.

– Алар арасында махсус хәрби операция зонасында бурычын үтәп кайтучылар да, якыннары янына кыска вакытлы ялга кайтучылар да бар. Алар бәйрәм чараларында да актив катнашачак. Ветераннарга да котлау сүзләре җиткерәчәк, – дип сөйләде ул журналистлар белән очрашуда. – Быелгы бәйрәм чаралары «Без – Бөек Җиңү варислары» дигән шигарь астында уза. Без тарихыбызны бозып күрсәтүгә, совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүен башкача аңлауларга юл куймаска тиеш.

Татарстанда яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннары

	2018	2023
Бөек Ватан сугышы инвалидлары	525	59
Бөек Ватан сугышында катнашучылар	1066	172
Гамәлдәге армия составына кермәгән Бөек Ватан сугышында катнашканнар	411	68
«Блокадалы Ленинградта яшәүче» тамгасы белән бүләкләнүчеләр	173	95
Балигъ булмаган әлеккеге тоткыннар	188	102
Тыл хезмәтчәннәре	33378	10218
Бөек Ватан сугышы тол хатыннары	3384	1614
Берьюлы ике категориягә ия булган кешеләр	7256	1949
Барлыгы	46381	14277

Ишегалдында да концерт

Республиканың мәдәният оешмалары быел Җиңү көне уңаеннан 350ләп чара әзерләгән. Алар 9 майда гына түгел, май азагына кадәр уздырылачак. Аерым алганда, ай дәвамында республикада Бөек Җиңүгә багышланган патриотик фестивальләр, күргәзмә, спектакль, очрашулар оештырырга җыеналар. Бәйрәмгә кадәр республикадагы барлык мемориал, һәйкәл һәм скверлар да тәртипкә китерелгән.

9 Май – Җиңү көнендә узачак төп бәйрәм чаралары исә елдагыча Арча һәм Архангел зиратларындагы хәрби каберлекләргә чәчәк салудан башланачак. Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин сүзләренә караганда, Җиңү паркындагы Мәңгелек ут, тыл хезмәтчәннәренә һәм солдат һәйкәлләренә дә чәчәк салыначак. Иң төп бәйрәм чаралары исә Меңьеллык мәйданында үтәчәк. Кичке сәгать алтыда бирелә «Җырлы Казан» дип исемләнгән концерт башланачак. Ул кичке сәгать унда бәйрәм салюты белән тәмамланачак. Ул «Казан» гаиләүзәге белән Кремль яр буенда яхшы күренәчәк, дип ышандыра оештыручылар.

Бәйрәм көннәрендә республикада бик күп төрле акцияләр дә узачак. Әйтик, быел Татарстанда кабат «Ветераннар йорты каршында парад» дип исемләнгән акция узачак. Хәтерләсәгез, әлеге акция беренче тапкыр 2020 елда оештырылган иде. Пандемия аркасында өлкәннәргә өйдән чыгарга киңәш ителмәгәч, артистлар һәм иҗат коллективлары үзләре аларның ишегалдына килеп, бәйрәм кәефе бүләк иткән иде. Ләйлә Фазлыева сүзләренә караганда, ветераннар бу чараны быел да уздыруларын сораган.

– Йорт ишегалдында уздырылган мондый концертлар ветераннарның күңеленә аеруча хуш килде. Алар бу акцияне быел да уздыруны сорады. Шуңа күрә ветераннар яшәгән йорт ишегалларында быел да бәйрәм концерты, парад гөрләячәк, – дип сөйләде ул.

Ахыры 2 нче биттә >

Урманчылар яңгыр көтә

Яз коры килү сәбәпле, урманнарда киеренкелек хөкем сөрә. Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, Татарстанда янгынга каршы махсус режим гамәлдә булып килә. Моннан тыш, министр искәртеп үткәнчә, урманнарга керү чикләнгән. Яңгырлар тиешенчә яумаганлыктан, республикада – IV, урыны белән V класслы янгын куркынычы кертелгән. Ел башыннан бирле төбәктә урманнар белән чиктәш җирләрдә 633 янгын очрагы, 765 термик нокта (әйтик, торфның пыскып ятуы) теркәлгән. Быелгы термик нокталар саны узган елның шушы ук чорындагыга караганда – 4,6, янгыннар саны 4,3 тапкыр арткан.

Сүз уңаеннан, Татарстан урманнарында янгын куркынычының чиктән тыш зур булуы сәбәпле, синоптиклар кисәтүе инде өченче тапкыр озайтылган. 3–10 май чорында урманнарда югары (IV) һәм гадәттән тыш югары дәрәҗәдә (V класслы) янгын куркынычы сакланып кала. Урманнарда янгын куркынычы турында тәүге кисәтү быел 13–20 апрель чорына кертелгән иде.

Ярдәм артачак

Татарстанда ятимнәргә уку чорында социаль ярдәм чараларын киңәйткәннәр. Моңа кадәр дәүләт вузлары һәм махсус урта уку йортлары студентларына гына тиешле булган түләүләр хәзер мәктәп укучыларына да кагылачак. Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бу җәһәттән карар урнаштырылган. Документ нигезендә, укуын тәмамлаучы ятимнәргә өс киеме, аяк киеме, урын-җир кирәк-ярагы һ.б. сатып алу өчен – бер тапкыр 59337 сум, укуын тәмамлаганда – бер тапкыр 899 сум, дәреслекләр һәм уку кирәк-яраклары сатып алу өчен – бер елга 3210 сум, өс киеме, аяк киеме, урын-җир кирәк-ярагы һ.б. сатып алу өчен – бер елга 25289 сум, туклану өчен бер айга 7877 сум бирелә.

Югары уку йортлары студентлары өчен дәреслек сатып алуга пособие 8303 сум тәшкил итә. Шул ук вакытта аларга һәр ай саен 1046 сумнан 1110 сумга кадәр өстәмә стипендия түләнелә.

Республикада 2022 ел башында 9709 ятим бала исәпләнгән. Бу – балаларның 1,14 проценты. Әйтергә кирәк, соңгы берничә ел эчендә – иң түбән күрсәткеч.

Сүз уңаеннан, узган айда мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин быел төбәктә 930 ятимнең торак белән тәэмин ителәчәген белдергән.

Хәрбиләргә – бушлай

Махсус операциядә катнашучыларны иң кирәкле белгечлекләр буенча бушлай укытачаклар яки өстәмә һөнәргә өйрәтәчәкләр. Премьер-министр Михаил Мишустин бу җәһәттән боерыкка кул куйган. Хөкүмәтнең матбугат хезмәте телеграм-каналында хәбәр ителгәнчә, әлеге карар хәрби хәрәкәтләр барышында һәлак булганнарның гаилә әгъзаларына да кагыла.

Шулай итеп, алар Мәскәүнең Һөнәри белемне үстерү институтында, Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясендә, Томск дәүләт университетында бушлай белем алачак.

Укырга керү өчен гаризалар «Работа России» порталында рәсмиләштереләчәк. Мәгариф оешмалары чыгымнарын Хөкүмәт грантлар ярдәмендә каплаячак. Ә инде эш бирүчеләр мондый хезмәткәрләрне эшкә урнаштырган өчен субсидияләр алачак.

Җылыта

Татарстан 32 градус эсседән соң яңгырлы атмосфера йогынтысында калган. Майның беренче көнендә һава температурасы нормадан 10 градуска артыграк булса, кичә республикада термометрның терекөмеш баганасы +10...+17 градустан югары күтәрелмәгән. Пәнҗешәмбе һәм җомга – 4–5 майда янә җылыта. Көндез һава температурасы +20...+26, төнге сәгатьләрдә +6...+12 градус чикләрендә тирбәләчәк. Урыны белән яңгыр көтелә.

Синоптиклар хәбәр итүенчә, шимбә – 6 майда көндез +17...+22 градус җылы булачак.

Яңалык

Май ае үзгәрешләре

✓1 майдан пенсияне бары тик «Россия почтасы» гына өйгә китерәчәк яки касса аша биреп җибәрәчәк. Моңа кадәр бу эш белән, почтадан тыш, башка оешмалар да шөгыльләнгән. Шул ук вакытта кайберләре, кыенлыклар алдында калып, әйтик, язгы ташу чорында махсус техника таба алмыйча, ерактагы авылларга пенсияне вакытында китермәгән. Шуңа күрә хәзер акчаны фәкать почта гына өләшәчәк.

✓Хәрби хезмәткәрләрне һәм ихтыяриларны, шулай ук югары вазыйфа биләүчеләрне халыкара органнарның җинаять эзәрлекләве турында хаксыз карарларын үтәүгә ярдәм иткән өчен җаваплылык кертелә. Моның өчен биш елга кадәр иректән мәхрүм итү каралган. Ә моңа кадәр Президентка, чит илләрнең законсыз карарлары яки Россиягә каршы гамәлләре очрагында, илне һәм кешеләребезне яклау вәкаләтләрен биргән закон үз көченә кергән.

✓Пенсия туплaнмасы югалмаячак. Россия Казначылык хезмәтенә тупланма пенсия резервын булдыруга иминият взносларын урнаштыру вәкаләтләре тапшырыла. Закон пенсия тупланмасы югалмауны һәм, вакыты җиткәч, кешеләрнең үзләренә бирүне тәэмин итәргә тиеш.

✓Банкларга вафат булган клиентлары турында мәгълүматлар тапшырылачак. Салым федераль хезмәте үлгән кешене салым исәбеннән төшерү турында банкларга хәбәр итәргә тиеш. Шуннан соң кредит оешмалары аның счетлары буенча барлык исәп-хисапны туктатачак. Шул ук вакытта бу мәгълүматлар салым серенә кертелә. Шулай итеп, үзгәрешләр үлгән кешенең банк картасыннан файдалану мөмкинлеге бирмәячәк.

✓Террорчылык, диверсия һәм дәүләткә хыянәт иткән өчен җәза чаралары көчәйтелә. Мәсәлән, шпионлык иткән өчен, чит ил кешеләренә дәүләт сере булып торучы мәгълүматлар тапшырган өчен, дошман ягына күчкән өчен гомерлек төрмә җәзасы каралырга мөмкин.

✓Каты авырулы балаларга ярдәм итү максатыннан, махсус мәгълүмат ресурсы булдырыла. Анда даруларны, медицина кирәк-яраклары, техник реабилитация чараларын кайсы оешмалардан табып булу, кайтару вакыты турында мәгълүматлар күрсәтеләчәк.

✓Балаларга вейплар сату тыела. Балигъ булмаганнарны тәмәке, кальян һ.б. тартуга җәлеп иткән өчен штраф күләме 5 мең сумга җиткерелә. Ә әти-әниләрне шундый ук гамәле өчен 7 мең сумга кадәр акчасыннан колак кактырачаклар. Балаларга мондый продукция һәм җайланмалар саткан өчен дә җәза чарасы кырысландырыла: штраф 600 мең сумга кадәр тәшкил итәчәк. Моңа кадәр балаларга вейплар (шул исәптән никотинсыз) һәм аларга кирәк-яраклар сатуны тыйган закон үз көченә кергән.

✓Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм чаралары алу гадиләштерелә. Хәрби хезмәткәрнең кайда икәнлеге турында алты ай буе хәбәр булмаса, ул, суд тәртибендә, хәбәрсез югалган, дип танылырга мөмкин. Махсус операциядә катнашучының үлеме турында белешмәләрне медицина оешмалары гына түгел, вәкаләтле затлар да бирә алачак. Туганнарының социаль түләүләр алуын җиңеләйтәчәк бу.

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Дәүләт Думасы Рәисе:

Күргәнебезчә, социаль челтәрләрдә тормышка өйрәтеп, кешеләрне ышандыру юлы белән зур акчалар эшләп, соңыннан, салымнар түләмәс өчен, төрле схемалар кулланучылар бар. Бу мәсьәләләрне Салым федераль хезмәтенең контрольдә тотуы бик дөрес. Миңа калса, ул кешеләрдән алынган акча мәктәпләрне, хастаханәләрне төзекләндерүгә, безнең солдатларга һәм офицерларга, аларның гаиләләренә ярдәм итү өчен тотылырга тиеш.

(«Телеграм»дагы каналыннан)

РОССИЯДӘ – ТӘМӘКЕ ТАРТУЧЫЛАР

Тәмәкене иң күп тартучылар
40–49 яшьлекләр >> 29%

14 яшьтән өлкәнрәкләр
2019 ел >> 23%
2020 ел >> 19%

Ир-ат тартучылар >> 37%
Хатын-кызлар >> 10%

Росстат мәгълүматлары буенча



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТӨРЕК САЙЛАВЫ АЛДЫННАН

Үткән атна капитализмның үз һәлакәтенә таба яңа адымнары белән тарихка кереп калды. Озак азапланганнан соң, Американың зурлыгы ягыннан ундүртенче банкы First Republic Bank җан тәслим кылды. Аны финанс акулаларының берсе JPMorgan Chase үз файдасына йотты. Бу йотылуда гаҗәп хәлләр бар, әмма, урын аз булганлыктан, без аларга тукталмыйбыз. Американың финанс кырыннан дәһшәтле хәбәрләр килүен дәвам итә. Чыганаклар американнар банк депозитларындагы акчаларын тарихтагы иң зур тизлектә чыгаралар дип хәбәр итә. Нәтиҗәдә тагын бер банк Valley National Bancorp – «Кремний үзәне банкы» бугазына элмәк салынды. Дүшәмбе көнне аның акцияләре 19 процентка очсызланды. Алдагы айларның тәҗрибәсе күрсәтә: егыла башладымы, банк тора алмый.

Доллар башы өстендә яшеннәр елтырый. Һиндстанның иң эре хосусый банкларының берсе – Kotak Mahindra Bank җитәкчесе долларны «дөньядагы иң эре финанс террорчысы» дип атады. Өченче дөнья илләрендә ул кәгазьләрнең чын асылын аңлау процессы бара. Халыкара валюта фонды җитәкчесе Кристалина Георгиева да дөньяның акрынлап доллардан баш тартуын таныды. Әмма фанфаралар кагарга иртә. Доллар – һаман да төп резерв валютасы. Элек аның өлешенә дөнья резервларының 70 проценты туры килсә, хәзер – 60 процент. Америкадагы банк түнтәрелеше кызуланса, доллар да үз позицияләрен югалтыр, мөгаен. Әмма хәзерге финанс системасы аны алыштырырлык башка валюта тудыра алмый. Начарны тагын да начарракка алыштырып кына була. «Банклар «начар кредитлар» йөге астында, шуның аркасында Американың коммерцияле күчемсез милек базарында бәяләр төшү шартларында давыл яралып килә», – диде Berkshire Hathaway (Американың холдинг компаниясе) вице-рәисе Мангер.

Глобаль кризисның көчәюе һәм конфликтлар арту фонында сәясәттә игътибарны якынлашып килүче төрек сайлавы җәлеп итә. Кем җиңүенә бәйле рәвештә зур шахмат тактасында диспозицияләр үзгәрергә мөмкин. Үткән атнада Әрдоганның хәле туры эфирда начарайганнан соң, мәгълүмат кыры имеш-мимешләр белән тулды. Төрек лидеры, Путин шикелле үк, авыр хәлдә, дигән сүзләр таратылды. Путин сүзчесе Песков хәбәрләрнең Кремль лидерына бәйлесен рәсми рәвештә кире какты: Президентның хәле бик яхшы, аның игезәкләре юк, бункерда качып утырмый, дигән белдерү ясады. Әрдоган исә җәмәгатьчелеккә чыгып басып, үзенең яхшы формада булуын раслады. 1 майда Измирда – оппозициянең төп ныгытмасы булган шәһәрдә Әрдоган яклы митингта халык диңгез булып чайкала иде. Моны гамәлдәге лидерның уңышы буларак бәяләделәр. Оппозиция лидеры Кылычдароглуның күрсәткечләре Әрдоганнан берничә пунктка яхшырак. Андый шартларда гамәлдәге лидер, эчендә җаны булса, тик ята алмый, билгеле. Әнкарада Президентны яклап җыелган митинг та масштаблы иде. Газета хәбәрчесенең танышлары Әнкарадан билетлар юклыгы сәбәпле кайтып китә алмауларын хәбәр иттеләр. Төрек сайлавы нәтиҗәләре глобаль сәясәткә зур йогынты ясаячак.

Россиядә

ХӘЛЛӘР ЯХШЫ, ӘММА НАЧАРАЯ

Украина зур һөҗүм булачак дип игълан итү шартларында Россия халыкара мәйданда үз позицияләрен шактый югалтты. БМОда Россиягә каршы резолюция кабул ителде. БМО резолюцияләре юридик көчкә ия булмый гадәттә, кечкенә генә илләр дә үзләренә каршы кабул ителгән карарларны үтәмиләр. Ләкин мәгълүмат кыры өчен мөһим алар. БМОның соңгы резолюциясенең тагын бер әһәмияте: анда беренче тапкыр Кытай Мәскәүгә каршы тавыш бирде. Моңарчы Пекин андый тавыш бирүләр вакытында тыелып кала иде. Бу Көнбатыш лидерларының Кытайга соңгы сәяхәтләре уңышлы тәгәлләнүен раслый. Европалылар кытайлы лидерларга ниндидер бонуслар вәгъдә итте шикелле. Пекин үз позициясендә кискен борылыш ясады. Си Цзиньпинның Зеленскийга шалтыратуы һәм Украинаны «стратегик партнер» дип атавы да шул хакта сөйли. Ул хакта Кытайның рәсми Синьхуа агентлыгы хәбәр итә. Россиянең рәсми матбугатында бу уңайдан «Председатель КНР обсудил с Зеленским то, что не обсуждал с Путиным» дигән баш астында хәбәр күренде. Бу Россия – Украина конфликты тирәсендә интриганы көчәйтә.

Мәскәүдән эчке сәясәт-икътисад өлкәсендәге хәбәрләр дә артык сөенечле түгел. Росстат нефть сәнәгатенә бәйле яңалыкларны 2024 елга кадәр яшерде. Бу углеводородлар чыгару өлкәсендә хәлләр җитди булуын дәлилли. Финанс министры Силуанов әфәнде дә яшереп тормый: «Нефть-газ безне аяктан ега», – дип белдерә. Ул федераль бюджетның дефициты фаразланганга караганда зуррак булачагын да таныды. Бик зур яңалык юк ул сүзләрдә. Без гыйнварда ук бу хакта язган идек. Ул чакта ук искәрттек: хәл начарая, әмма котчыккыч түгел, дидек. Хәзер дә шуны кабатлыйбыз. 2023 елда Россиядә социаль чыгымнарны капларга да, махсус хәрби операциягә дә акча җитәчәк. Ниндидер кискен үзгәрешләр булмаса, билгеле. Әмма бер нәрсә бар. Вазгыять мәшһүр бер язучының: «Как на грех, дела в колхозе шли плохо. То есть не так чтобы очень плохо, можно было бы даже сказать – хорошо, но с каждым годом все хуже и хуже» дигән афоризмындагыча үсә. Үзәк банк рәисе Нәбиуллина инфляциянең көчәячәге турында рәсми белдерү ясады. Ул белдерүдән башка да аңлыйбыз: бюджет дефициты үсә, ә инфляция – шул дефицитны каплауның бер чарасы. Ямьсез һәм күңелсез чара, әлбәттә, әмма нишлисең.

Газ тармагы да бер дә сөендерми. «Известия» 2023 ел йомгаклары буенча газ экспорты 50 миллиард кубометрга кадәр түбәнәячәк дип фаразлый. Бу Брежнев чоры күрсәткечләреннән дә түбәнрәк. Яңа Россия тарихында газ экспорты 110 миллиард кубометрдан да түбән булмады, 200 миллиардлык үрләр яуланган еллар да бар иде.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЯЗНЫҢ БЕР КӨНЕ

Чәчү мәйданнары, фермада эшләүче роботлар, ял һәм сөт бәясе. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың Мөслим, Минзәлә, Тукай һәм Түбән Кама районнарында язгы кыр эшләре барышы белән танышты. Вертолеттан төшкәч, районда яшәүчеләр белән очрашып, аларның хәлен дә белеште ул. Республика кырларында эш турында да, аш турында да сөйләштеләр.

tatarstan.ru

Эш сәфәрендә Рөстәм Миңнехановны Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров озатып йөрде. Кунакларны беренчеләрдән булып каршы алган Мөслим районы башлыгы Альберт Хуҗин әйтүенчә, районда чәчү мәйданы 75 мең гектар тәшкил итә. Шуның 59 мең гектары сабан культураларына туры килә. Барлык кырларның 82 процентында чәчү эшләрен тәмамлаганнар инде. Тагын 3–4 көннән эшне тулысынча тәмамларга ниятлиләр. Марат Җәббаров сүзләренә караганда, авыл хуҗалыгының нәтиҗәлелеге буенча Мөслим районы республика күләмендә алтынчы урында тора. Соңгы ике елда гына да район сигез баскычка югары күтәрелгән. Тармакка бәйле борчыган сораулар да бар, әлбәттә. Министр шәхси хуҗалыкларда мөгезле эре терлек саны кимүен әйтте һәм халыкка дәүләттән ярдәм чаралары турында тагын бер кат аңлатырга киңәш итте. Тулаем алганда, Рөстәм Миңнеханов, районда эш яхшы оештырылган, дип бәя бирде.

Мөслимдә Рәис заманча «Август-Мөслим» сөтчелек комплексында да булды. Биредә сыерларны 18 робот сава. Мондый фермалар Татарстанда гына түгел, ил күләмендә дә бик сирәк. Комплекста 4 меңнән артык мөгезле эре терлек исәпләнә. Шуларның яртысы – савым сыерлары. Биредә тәүлегенә 63 тоннадан да күбрәк сөт савалар.

Минзәлә районы башлыгы Айдар Сәлахов әйтүенчә, районның авыл хуҗалыгы җирләре 98 мең гектарга якын мәйданны алып тора. Чәчү эшләре график нигезендә алып барыла, дип хисап тотты «глава» Рөстәм Миңнехановка. Аның сүзләренә караганда, Минзәләдә терлекчелек комплекслары төзү юнәлешендә зур эш алып барыла. Үсемлекчелек һәм әлеге тармакларда заманча технологияләрдән файдалану турында да онытмыйлар. Районда Рөстәм Миңнеханов авыл хезмәтчәннәре белән дә аралашты. Ул аларга башкарган эшләре өчен рәхмәт әйтте.

Рәискә райондагы «Камский Бекон» сөтчелек комплексын да күрсәттеләр. Биредә 8600дән артык мөгезле эре терлек исәпләнә. Комплекста былтыр 10 мең тонна сөт һәм 270 мең тонна ит җитештергәннәр.

Тукай районында да язгы чәчүне атна ахырына кадәр төгәлләмәкчеләр. Районда барлык кырларның 72 процентында, ягъни 42 мең гектар мәйданда эш беткән инде. Тукай районы башлыгы Фаил Камаев сүзләренә караганда, хуҗалыклар кирәкле техника, ягулык-майлау материаллары һәм ашлама белән тәэмин ителгән. Былтыр игенчеләр 187,8 мең тонна ашлык җыйган. Быел да кимен куймаска тырышалар. Рөстәм Миңнеханов районның уңышларын югары бәяләде. Шулай булмый ди, Тукай районы авыл хуҗалыгының нәтиҗәлелеге рейтингында беренче урында тора.

– Җирле хуҗалыклар бөтен юнәлешләрдә дә тырышып эшли. Терлекчелек буенча да, үсемлекчелектә дә үсеш күзәтелә. Район шәхси хуҗалыклар саны буенча да сынатмый, – диде министр.

Рөстәм Миңнеханов районның Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләре янәшәсендә урнашуын да искәртте.

– Бу сезгә өстәмә мөмкинлекләр ача, – диде Рәис. – Әйе, хәзер катлаулы чор. Моңа да карамастан, республикадагы барлык проектлар һәм программалар дәвам иттерелә.

Мисал эзләп ерак йөрисе дә юк. Рөстәм Миңнеханов районның Яңа бистәсендәге ял паркында булды. Әлеге иҗтимагый киңлек уңайлы шәһәр мохитен булдыру юнәлешендә республика бюджетыннан бүлеп бирелгән акчага төзелгән. Паркта мәдәният йорты, Дан аллеясы һәм спорт мәйданчыгы бар. Рөстәм Миңнеханов Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә куелган һәйкәлгә һәм Габдулла Тукай һәйкәленә чәчәкләр салды. Районда яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннары белән дә аралашты. Бүген биредә сугыш шаһиты булган алты ветеран яши.

Түбән Камада вазгыять тотрыклы, диде район башлыгы Рамил Муллин кырлардагы эш барышы белән танышырга килгән Рөстәм Миңнехановка. Бүген районда 65 фермер хуҗалыгы эшли. Чәчүгә бәйле төп эшләр дә ахырына якынлашып килә. Марат Җәббаров сүзләренә караганда, авыл хуҗалыгының нәтиҗәлелеге буенча Түбән Кама районы республика күләмендә унберенче урында тора. Кыр эшләрендә катнашучылар белән очрашкач, Рөстәм Миңнеханов авыл хезмәтчәннәреннән эш шартлары белән дә кызыксынды. Форсаттан файдаланып, Рәистән авыл халкының үзәгенә үткән мәсьәлә – сөтне кабул итү бәясе турында сорадылар. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, ул бу хакта хәбәрдар. «Без бу мәсьәләдә федераль дәрәҗәдә сөйләшергә әзер», – диде ул.

P.S. Казанда исә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов республиканың Урман хуҗалыгы министрлыгына урман патруле машиналары тапшырды. «Тимер ат»ларны федераль программа ярдәмендә сатып алганнар. Бу уңайдан, Рөстәм Миңнеханов Россия Табигать һәм экология министрлыгына рәхмәт белдерде. «Заманча транспорт чаралары урманчыларның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен кирәк», – диде ул. Татарстан урманчылары белән горурлануын да әйтте.

Тынычлык хакы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кеше күп җыела торган урыннарда, дәүләт оешмаларында бәйрәм чараларында елдагыча Георгий тасмасы таратылачак. Республикадагы торак йорт һәм офис биналарына Җиңү байрагы эленәчәк. «Җиңү тәрәзәләре» акциясе кысасында елдагыча белем бирү, социаль оешмалар тәрәзәләре дә бәйрәмчә бизәләчәк.

Башка еллардан аермалы буларак, быел ил күләмендә «Үлемсез полк» йөреше булмаячак. Куркынычсызлык максатыннан шундый карар кабул ителде. Бөек Ватан сугышында катнашкан каһарман бабайлар турында сөйләүнең быел башка ысулларын тәкъдим итәләр. «Ветеранның сурәтен машинага, киемгә яки бейджикка урнаштырырга була, шулай ук социаль челтәрләрдә аватарларга да шушы фотоны куярга мөмкин», – ди оештыручылар.

Саклану чаралары

Бәйрәм чаралары вакытында куркынычсызлык мәсьәләсенә аеруча зур игътибар биреләчәк. 4 меңнән артык хокук сакчысы, 300ләп Росгвардия хезмәткәре, 1 меңләп иҗтимагый берләшмә вәкиле тәртип сагында торачак. Бәйрәм чараларында 800 мең чамасы кеше катнашыр дип көтелә. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының иҗтимагый тәртип саклау бүлеге башлыгы Фәргать Мөхәммәтҗанов сүзләренә караганда, полиция хезмәткәрләре 30 апрельдән үк көчәйтелгән режимда эшли башлаган.

– Террорчылыкка каршы куркынычсызлык чараларына аеруча зур игътибар биреләчәк. Чара узачак урынны махсус этләр ярдәмендә тикшереп чыгачаклар. Бәйрәмгә килүчеләрне дә тикшереп кертәчәкләр, – ди ул.

Оештыручылар халык күпләп җыелган урыннарга зур букча белән килергә дә киңәш итми. Сәер әйберләр, зур букча тапкан, шикле кешеләр очраткан очракта да тиз арада хокук сакчыларына хәбәр итәсе. Фәргать Мөхәммәтҗанов махсус хәрби операциягә бәйле рәвешле республикада дрон, квадрокоптер ише җиһазлар куллану тыелганын да искә төшерде. Бу хакта бәйрәм чараларында гына түгел, озын ялларда да истән чыгарасы түгел.

– Без бүген башка чорда яшибез. Махсус хәрби операция зонасыннан ерак җирдә яшәсәк тә, куркыныч яный, – ди Фәргать Мөхәммәтҗанов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЭШЕ ДӘ, АШЫ ДА ҖИТӘРЛЕК

Яшәргә өйрәнәбез

«Авылдан китү дигән җөмлә минем өчен бөтенләй юк. Ул сүзләр миңа хәтта сәер яңгырый». Саба районының Сатыш авылында яшәүче яшь фермер Илфир Садыйков безнең: «Ничек авылда калырга булдыгыз?» – дигән соравыбызга каршы әнә шулай диде.

– Әти-әнием гомер-гомергә терлек тотты. Шуңа күрә терлекчелек – минем өчен табигый күренеш. Бервакытта да шәһәргә китү турында уйлаганым булмады. «Ни өчен авылда калдың?» – дип сорасалар, сискәнеп китәм хәтта. Чөнки бу сорау миңа бөтенләй аңлашылмый, – ди Илфир.

Хатыны, үзе кебек үк тырыш Гүзәл белән бергә алар башта төп йортта, әти-әни һәм дәү әбиләре белән яшиләр. 4 ел элек төп нигез янәшәсендә генә зур, матур йорт җиткезеп, башка чыкканнар. Нигезне тагын да ямьләп дүрт балалары – өч кызлары һәм бер уллары тәгәрәшеп үсә. Йортлар аерым булса да, тормыш итү бергә, дип әйтергә дә мөмкин. Хуҗабикә Гүзәл балалар, өй мәшәкатьләре белән кайнашканда, терлек карау – гаилә башлыгы җаваплылыгында. 120 гектар җирдә иген игеп, утызлап баш сыер тота Садыйковлар.

– Без хуҗалыкта бөтен эшне үз көчебез белән генә эшлибез. Терлек азыгын әзерләүдән башлап, сыер саву, асларын чистартуга кадәр. Сыерларны саварга әнием булыша. Үзебез эшләгәнгә күрә тормышыбыз бара да инде. Чөнки авыл хуҗалыгы күп чыгым сорый. Азыгын сатып ала башласаң, ерак китеп булмый. Бәяләр артып кына тора. Ә сөт бәяләре түбән тәгәри. Язга чыккач кына да хаклар литрына 8 сумга төште. Әле без турыдан-туры заводка тапшырабыз. Халык тагын да арзанрак бәядән сатарга мәҗбүр, – ди Илфир.

«Бары тик үз көчеңә генә ышанырга». Әлеге гаиләнең тагын бер тормыш девизы бу. Хуҗалыкларын да үзләре алып баралар, матур йортларының проектын да үзләре башкарып чыкканнар. Шуңа күрә Илфир шаяртып үзен «төзүче-авантюрист» дип тә әйтә.

– Җирдә эшләү дә, хәләл хезмәт тә каныбызга сеңгән. Беркем дә, менә монысын болай ит, тегесен тегеләй, дип өйрәтеп торганы булмады. Барысы да тәҗрибә белән килә. Аннан соң, физик хезмәттән курыкканнар авылда кала алмый. Монда яшәр өчен аны яратырга да, тырыш та булырга кирәк. Тырышмыйча гына бернинди дә уңышка ирешеп булмый. Без исә сайлаган юлыбыздан бер адым да артка чигенмибез. Безгә эшләп яшәү ошый, – ди гаилә башлыгы.

Ире хуҗалык эшләрен алып барганда, хуҗабикә Гүзәл бер дә тик тормый. Берсеннән-берсе кечкенә дүрт баланы карау өстенә, әледән-әле яңа һөнәрләр үзләштереп, үзен яңа яктан ача. Сырын да ясый, шоколадын да кайната.

– Әлегә балалар белән вакыт җитмәгәнлектән, сыр ясауны беразга туктатып торырга туры килде. Югыйсә бик яратып алалар иде аны. Әле дә сорыйлар. Чын сөттән ясалган сырны ашап карагач, кибетнекен ашыйсы килми, диләр. Сырны башта кәстрүлдә генә ясадык. Сораучылар саны арткач, сыр кайнату җайланмасын алырга туры килде, – ди Гүзәл.

Ул өендә «Адыгей», «Сулугуни» кебек йомшак сырлар да, «Качотта» дип аталган итальян сырын да ясый.

Өй шартларында шоколад ясый башлавы исә – дөрес туклану белән кызыксыну нәтиҗәсе.

– Балалар шоколад ярата. Ә сыйфатсыз ризык бирәсе килми. Шуңа күрә үземә шоколад әзерләү серләренә төшенергә туры килде. Шикәрсез, бары тик файдалы ингредиентлар кушып кына шоколад ясарга өйрәндем. Кешеләр аны да бик яратып ала, – ди ул.

Менә шулай балаларны да тырыш хезмәт үрнәгендә тәрбиялиләр.

– Хәзер акча эшләү урынга бөтенләй бәйләнмәгән, – ди Гүзәл. – Кулындагы телефонына интернет тоташкан икән, әллә никадәр эшкә өйрәнеп була. Теләк кенә кирәк. Сыр ясарга тәҗрибәле белгечнең дәресләрен карап өйрәндем. Димәк, авылда да рәхәтләнеп яшәргә мөмкин. Авыл халкы нәрсәдәндер мәхрүм кала, дип уйлау дөреслеккә бөтенләй туры килми. Шәһәр дип алданырга кирәкми. Авылда эше дә, ризыгы да, мавыгуы да җитәрлек.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕР МАНДАТЛЫ САЙЛАУ ОКРУГЫ БУЕНЧА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНА ӨСТӘМӘ САЙЛАУГА ТЕРКӘЛГӘН КАНДИДАТЛАРНЫҢ САЙЛАУ АЛДЫ АГИТАЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ

МАТЕРИАЛЛАР АВТОР ӘШКӘРТҮЕНДӘ БАСТЫРЫЛА. АЛАРНЫ ГАЗЕТА БИТЛӘРЕНДӘ УРНАШТЫРУ БАСМА МӘЙДАН БҮЛҮ БУЕНЧА ҮТКӘРЕЛГӘН ҖИРӘБӘ НӘТИҖӘЛӘРЕНӘ ТУРЫ КИЛӘ

№ 20 Электротехник
бер мандатлы сайлау округы

ТАТЬЯНА
МУХИНА

КПРФ

Теркәлгән кандидат Мухина Т.А.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 20 Электротехник
бер мандатлы сайлау округы

АЛЕКСАНДР
БЫКОВ

Хәрби хәрәкәтләр ветераны, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән

ПАРТИЯ НОВЫЕ ЛЮДИ

- Кешеләр әһәмиятлерәк!
- Бөтен Татарстанны үстерергә!
- Үзгәрешләр энергиясе.

Теркәлгән кандидат Быков А.В.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

№ 20 Электротехник
бер мандатлы сайлау округы

ДИСТАНЦИОНКАГА, ОПТИМИЗАЦИЯГӘ – ЮК!

РОССИЯНЕҢ СЫЙФАТЛЫ БЕЛЕМЕНӘ – ӘЙЕ!

Илнар СИРАЕВ

Кандидат в депутаты Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва по Электротехническому одномандатному избирательному округу № 20

СР СПРАВЕДЛИВАЯ РОССИЯ ПАТРИОТЫ ЗА ПРАВДУ

Теркәлгән кандидат Сираев И.Р.
Агитация материалы. Татарстан Сайлау кодексының 62 маддәсе нигезендә бушлай бастырыла.

СИҢА БӘХЕТ ТИЕШ, КЫЗ БАЛА...

Борчыган мәсьәлә

Кыз баланы ничек тәрбияләргә? Бәйсез, тигез хокуклы, кыерсытканга җавап бирүче итепме? Әмма бу сыйфатлар аңарда хатын-кыз нәзакәтлеген, йомшаклыгын юкка чыгармыймы соң? Шул ук вакытта җайлы бала үстерү дә дөрес түгел кебек. Без әнә шул хакта сөйләштек.

Кызларның үз көе

Казанда яшәүче Гөлнур Мәхмүтованың алты баласы бар. Дүртесе – кызлар. Иң кечесенә – 5, олысына – 22 яшь.

– Миңа калса, кызларны тәрбияләү авыррак. Ник дигәндә, алар көйсезрәк, елаграк, һавада очарга ярата. Кызлар да бер-берсе белән төрткәләшә. Бала бала инде ул. Аларны дин кушканча һәм «әтиегез ни әйтер» дип тәрбиялим. Апалары – командир. Ул сеңелкәш-энекәшләренә эш куша һәм җиренә җиткереп үтәтә. Ялкаулык яхшы нәрсә түгел бит. Эшләп үсмәсәләр, балаларын киләчәктә нәрсәгә өйрәтерләр? – ди Гөлнур Мәхмүтова.

Ике бала әнисе, журналист Лилия Гәрәева фикеренчә, бәхетле кешеләрне бәхетле әниләр үстерә. Ул хатын-кыз җайлы булмаска тиеш дип саный. Кызына – 17 яшь.

– Әни мине бик уңайлы кеше итеп тәрбияләде. Кушканны эшләргә, бәхәсләшмәскә, ул теккән күлмәкне кияргә, кычкырып көлмәскә, укытучыны тыңларга... Каршы әйтү, фикереңне белдерү әдәпсезлек иде, минемчә. Үзем турында беркайчан да уйлый белмәдем. Кияүгә чыккач, уңайлы хатынга әйләндем. 40 яшьтән соң гына дөрес яшәмәвемне аңладым. Үзеңне корбан итүне беркем дә бәяләми, – ди Лилия. – Мин балаларыма беркайчан да үз фикеремне такмадым. Әни тәрбияләгәннең киресен эшләдем. Кызым Зиләне уңайлы итеп үстермәскә булдым. 12 яшьтә үзе бокс түгәрәгенә китте. Хәзер Россия җыелма командасы составында чыгыш ясый. Яшермим, ул – укытучылар өчен дә, безнең өчен дә уңайсыз бала. Аның үз фикере бар. Барлык ярышларда катнашкач, укырга вакыты калмый. Ярышларда сынмаган бер сөяге дә калмады. Авырса да, шөгыльләнен калдырмый. Тренерыннан башка беркемнән дә курыкмый. Милли җанлы булып үсә. Безнең халыкта кызларны, кит аннан, болай булсаң, сине кияүгә дә алмаслар, дип түбәнсетеп тәрбиялиләр. Аңлы кеше кызларын күтәрә.

Дөнья куа хатыннар

«Татар гаиләсе» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Әлмәт бүлеге җитәкчесе Гөлия Җамалетдинова белдергәнчә, хатын-кызның усалллануы тормышны үз җилкәсендә күтәрүгә бәйле. Уңышлы ир-ат артында да – көчле хатын-кыз кулы.

– Хатын-кыз ирләргә караганда усалрак, чөнки тормышта күп нәрсәне үзе тарта. Шуңа күрә ул йомшак була алмый. Бушка фатир бирмиләр, күп кеше ипотека түли. Акча җитми. Бала барысын да күреп үсә. Яшьләрдә максимализм көчле. Аларга барысы да бүген кирәк. Монысы – Көнбатыштан кергән һәм башка сеңдерелгән фикер. Без исә бүгенгенең кадерен белеп, киләчәккә өметләнеп үстек. Нәрсә булса, шуннан тәм таптык, – ди ул.

Гөлия Җамалетдинова әйтүенчә, балага ана назы кирәк. Әтисе белән яхшы мөнәсәбәттә булса, бәхетле була. Бүген ялгыз бала үстерүче аналар да күп. Алар назын да, җылысын да җиткереп бетерә алмаска мөмкин. Әтиләр үз вазыйфаларын башкармаган очракта да кыз бала яклаучысыз кала. Гаилә бөтенлеге, иминлеге дә зур әһәмияткә ия. Бер-береңне ихлас ярату, эчкерсез мөнәсәбәтләр булганда кеше бәхетле.

Хатын-кыз бөтен авырлыкны үз өстенә алырга тиешме? Бу сорауны Россиянең атказанган, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты Салават Фәтхетдиновка бирдек.

– Бу – дөньякүләм проблема. Ирләр хатын-кызга әйләнгәч, хатын-кызлар нишләсен соң? Иргә әйләнә инде. Ир – ир, хатын хатын урынында булырга, без, татарлар, башка милләтләрдән аерылып торырга тиеш. Иң мөһиме – шул. Безгә башка милләтләргә ияреге ярамый, дип яшәргә кирәк. Безнең үз тарихыбыз бар. Татарга хас закон булырга тиеш. Ислам дине законнарына таянырга кирәк. Анда начар бер нәрсә юк. Кыз баланы ничек тәрбияләргә дигән сорауга әниләр җавап бирергә тиеш. Әни булып караган кеше түгел, – диде Салават Фәтхетдинов.

Сәрия МИФТАХОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

Фикер

Илсөяр ГАРИФУЛЛИНА, республика балигъ булмаганнар эшләре һәм балалар хокукларын яклау комиссиясе җаваплы секретаре:
– Кыз баланы әниләр тәрбияләргә тиеш. Сүз белән генә түгел, үзенең шәхси үрнәге белән. Үзеңне кеше күңелләштерерлек итеп куйма! Тегеләй, болай эшләмә дип, тискәре мисаллар китереп кенә тәрбияләүдән файда юк. Баланың киресен эшләп карыйсы килә. Дорфалык дорфа итеп тәрбияләүдән килә. Гаиләдә дә, мәктәптә дә әхлакый тәрбия белән шөгыльләнергә кирәк. Матбугатта яхшы әйберләр турында күбрәк язгыгыз. Начар мисаллар китереп, матур итеп тәрбияләп булмый. Балаларга бит, яхшы кешедән үрнәк ал, дип әйтәбез. Урамда сугышып йөргән кыздан үрнәк ал, димибез. Яхшы мисаллар да бик күп.

Җәмилә АБДУЛЛИНА, тугыз бала әнисе (Балтач районы Ярак-Чурма авылы):
– Биш кызыбыз бар. Тегене-моны эшлә дип түгел, менә миңа карап эшләгез, дип өйрәтәм. Алар бар үрнәкне гаиләдән ала. Башка чара юк. Кыз баланы хәзерге заманда иман ныклыгы белән генә саклап була дип уйлыйм. Балалар татар гимназиясенә йөри. Анда тәртип тә, әхлак дәресләре дә бар. Бу дәресләрне безгә кайтып сөйлиләр. Димәк, сеңдерәләр бит. Мин үзем – бик юаш әни. Әти кеше катырак булырга тиеш. Әтиләрнең дәрәҗәсе – әниләр кулында. Безнең гаиләдә әти сүзе – закон. Кызларны 7 яшькә кадәр – әни, ә аннан соң күбрәк әтиләр тәрбияләргә тиеш дип саныйм. Бу аларны ирләргә буйсынырга өйрәтү өчен кирәк.

Гөлнара ИБРАҺИМОВА, мәктәп психологы:
– Хәзер тәрбияләү дигән нәрсә бөтенләй юкка чыкты. Әти-әниләрнең үзләрен зурларча тота белмәвенә шаккатам. Балалар әти-әниләреннән өлкәнрәк кебек. Кайберләре тормышы уңмаган өчен балаларыннан үч ала. Гаиләдә ир белән хатын-кыз арасындагы рольләрнең җимерелә баруына бик борчылам. Хатын-кызларның уенда – акча эшләү. Элек гаиләдә түзү, юл кую дигән нәрсә бар иде. Хәзер бу нәрсәләрне күрмим. Гаиләләрдә аерылышулар күп. Хатын-кыз үзе бәхетле булмаса, баласын бәхетле итеп үстерә алмый. Башта үзеңә шуңа өйрәнергә кирәк. Әниләр кызларын тәмле телле, нәзакәтле, тормышка әзер итеп үстерсен иде. Укучылардан еш кына бурычлары турында сорыйм. Алар миңа: «Үзеңне яратырга кирәк», – диләр. Әлеге сүзне бик еш әйтәләр хәзер. Дөрес аңлагыз: үзеңне ярату кешене, якыннарыңны ярату өчен кирәк!

Вузлар мәктәпкә килә

Җаен табарга кирәк

Шәһәр балаларын авыл тормышы, табигать, урман кызыксындырмый дигән булалар тагын. Ничек кенә әле! Казан дәүләт аграр университеты ректоры Айрат Вәлиев кебек җаен-көен таба белергә генә кирәк.

Казанның Идел буе районындагы «Перспектива» дип аталган 186 нчы күппрофильле лицейда булган вакыйга барысын да аякка бастырды. Монда Казан дәүләт аграр университеты, лицей һәм Урман ягынры үзәге арасында үзара хезмәттәшлек итү турында өчьяклы килешү төзелде. Максатлары – укучыларга һөнәри юнәлеш бирү.

Әле тантаналы кичә башланганчы ук тәнәфескә чыккан укучылар белән аралашып алган идем. Барысы да үзенчә ниндидер яңалык көтә. Киләсе уку елыннан шушы документ нигезендә экологик юнәлештә 8–9 нчылар арасында аерым сыйныфлар тупларга ниятлиләр. Әти-әниләр белән дә сөйләшүләр булган. Берсе дә каршы килмәгән. Киресенчә, балаларының табигать кочагына якынрак булулары шатландырган гына аларны. Үзләре дә читтә калмаска ниятләп торалар.

186 нчы лицейда математика, химия, биология кебек юнәлешләр бар инде. Шул нисбәттән авиация, педагогика, медицина буенча белгечлекләр әзерләүче уку йортлары белән дә элемтәләре нык. «Әмма экологик тәрбия бик кирәк иде», – ди уку йорты директоры Азит Җамалдинов. Дөрес, моңа кадәр дә бу темага игътибар зур булган. Лицейда «SOS» бригадасы эшләп килә. Бу юлы да тамашачылар алдында Казансу елгасының язмышы турында җиткерделәр. Тарих битләрен дә актардылар. 100 ел элек бу елганың нинди булуы барыбызда да кызыксыну уятты. Бүген яр буйларында берсеннән-берсе биегрәк корылмалар төзелә, болыннар кипterelә. Елга дәшми, аңа кем ярдәм итәр, дигән сорау гына әлегә җавапсыз калды.

Бу сорауларга хәзер җавапны, бәлки, Казан дәүләт аграр университеты белән бергәләп биреп булыр, дип өметләнә лицей укучылары. Югары уку йортының 100 еллыгына багышланган фильмны да бик игътибар белән карады алар. Минтимер Шәймиев, Рөстәм Миңнеханов кебек республика башлыкларының да нәкъ шул уку йортын тәмамлаганнарын белгәч, горурланып та куйдылар. Ректор аңлатма да биреп барды.

– Монда авыл хуҗалыгы турында гына сүз бармый. Бездә икътисад, инженер-техник, җир төзелеше, урман хуҗалыгы буенча да белем алырга мөмкин, – диде ул. – Без соңгы вакытта авыл мәктәпләренә генә түгел, бәлки, шәһәрнекеләргә күбрәк тә игътибар бирә башладык, чөнки төрле базалар, лабораторияләр нәкъ менә зур бистәләрдә, шәһәрләрдә урнашкан. Анда эшләүче кадрлар да бик кирәк.

Әлбәттә инде, бу кичәдә укучылар танышкан юнәлешләрнең берсе – урман хуҗалыгы. Урман – барыбер сер тулы дөнья инде ул. Шуңа күрә укучыларның нәкъ менә шушы дөнья белән күбрәк кызыксынулары юкка булмагандыр. Урман хуҗалыгы факультеты профессоры Харис абыйлары Мусинны да сулыш алмыйча тыңлады алар.

– Сезнең белән элемтәләр булдыруга без бигрәк тә шатбыз, – диде Харис Гайнетдинович. – Беренчедән, лицей аграр университет янәшәсендә, димәк, аралашу өчен җиңелрәк булачак, икенчедән, уку йортыгыз да шәһәр тузаныннан шактый читтә, урман эчендә диярлек урнашкан. Бу үзе үк сезгә табигать балалары булып үсәргә ярдәм итәчәк. Татарстан урманнары, белгечләр турында да бик кызыклы мәгълүматлар яңгырады. Татарстанда урманчылар моннан 135 ел элек әзерләнә башланган. 1888 елда Минзәлә өязендәге Биклән урманчылык мәктәбе башлаган бу эшне. Анда урман кондукторлары әзерләгәннәр. Хәзер ул мәктәп юк инде. Эстафетаны Кукмара районында урнашкан Лубян урман хуҗалыгы техникумы кабул итеп алган. Узган ел бу уку йорты 100 еллыгын бәйрәм итте. Бүген югары белемле белгечләрне аграр университетның урман хуҗалыгы факультеты әзерли.

Россиядә исә урман фәненә нигезне 1818 елда оештырылган Санкт-Петербург урман техник университеты салган. Безнең аграр университет бу уку йорты белән бик дустанә мөнәсәбәттә. Лубян техникумын тәмамлаганнан соң, бик күпләр укуын шунда дәвам итә икән. Элеккеге министрларыбыз Александр Гуляев, Наил Мәһдиев тә шунда белем алганнар. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов – әлеге университетның мактаулы академигы.

Урман эшләре буенча югары белем бирү эшләренең яңа этабы XX гасырның ахырында гына башлана. Моның кирәклеге турында инициатива белән профессорлар Әхмәдулла Газизуллин, Факил Әһлиуллин, Шәһәр яны урман хуҗалыгы директоры Харис Мусин, Татарстанның һәм Россиянең атказанган урманчысы Нургали Миңнеханов чыга. 2001 елда урман хуҗалыгы факультеты, ниһаять, булачак урманчыларга белем бирә башлый.

– Бүген безнең урманчылар Татарстанда гына түгел, Россиянең барлык төбәкләрендә, Казахстанда, Кыргызстанда хезмәт куя. Эшләр шуңа таба бар ки, киләчәктә, гомумән, Россиядәге барлык урманнар белән безнең укучылар идарә итәр кебек, – ди Харис Гайнетдинович. – Без моның белән бик тә горурланабыз.

Ул инде бүген үк укучыларны урман факультеты студентлары үстергән дендрарий, ягъни сирәк очрый торган агач-куаклар үстерелгән бакчага чакырды. Форсаттан файдаланып, мәктәп укучылары урман белгечлеге алырга җыенган абый-апалары белән дә сөйләшерләр, киңәш-табыш кору зыян итмәс.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

Татарстан Республикасы **6** млн **800** мең гектар чамасы мәйдан били, шуның нибары **1** млн **271** мең гектары, ягъни **17** проценттан бераз артыгы – урманнар. Аларның **16** проценты – ылыслы, **59** проценты – яфраклы агачлардан торган катнаш урманнар.

Чүплеккә әйләнмәсен

Чистарту икеайлыгы

Чисталык капка төбеннән башлана! Сарман районының Ләшәү-Тамак авылында яшәүче Ханнановлар моны яхшы белә. Аларның капка төбе генә түгел, йортларының һәр почмагы тәртиптә. Әле алай гынамы, авылларындагы җыелып яткан чүп-чар өемнәре дә алардан «куркып» тора. Гаиләләре белән чисталык сагында торалар алар.

– Күңел шулай куша. Без үз артыбыздан башкаларны ияртә алуыбызга сөенәбез. Элек чүпне бушка да җыйдык. Ниндидер бүләк бирерләр дип уйлап та карамадык. Артыңнан җыясы бит инде аны. Үзебез пычратмасак та, яшәгән җиребез чиста булсын, дип тырыштык. Өч ел рәттән безнең эшне күреп, зур сәхнәләрдә бүләкләделәр. Ике балабыз да, кыйммәтле бүләкләр биргәч, тагын да тырышып чүп җыя, – ди Илнур Ханнанов.

Берәүләр җыя, икенчеләр әле дә кулындагы чүбен әрҗәгә ташларга өйрәнеп бетә алмый. Андыйларны өмәгә чакырырга кирәк, ди Казанның Вахитов районында яшәүче Фәүзия Насыйбуллина. 74 яшьтә булуына карамастан, ул да башкалар белән беррәттән өмәгә чыккан иде. Исегезгә төшерәбез: узган шимбәдә урманчылар агач утыртты, экологлар чүп җыйды.

– Телевизордан ишетеп килдем. Монда чүп җыюны уен төсле итеп оештырганнар икән. Яшьләрне өмәгә башкача тарту кыендыр инде. Үзебезнең йорт тирәсендә иртә яздан чәчәкләр үстерә башлыйм, көзгә кадәр чәчәк атып утыралар. Быел өмәдә катнашасым килде, – ди ул.

Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков сөйләвенчә, чистарту икеайлыгы кысасында үткәрелгән өмәдә Казанда яшәүче 700дән артык кеше катнашкан.

– Безгә республиканың төрле районнарында яшәүчеләр кушылды. Бу юлы Казан халкы үтенече буенча рус-немец Швейцариясе территориясен сайладык. Андагы чүп-чарга зарланып берничә тапкыр гариза керде. Елдан-ел безнең акцияләрдә катнашучылар саны арта, без аларның барысына да зур рәхмәтебезне әйтәбез, – ди Александр Шадриков. – Өмә «чиста уеннар» форматында узды, анда 154 команда катнашты. Гомуми тырышлык белән 733 капчык чүп-чар җыелды, шуның 240 капчыгы – пластик, 188е – пыяла, 82се металл иде. Без аларның барысын да икенчел эшкәртүгә җибәрәчәкбез.

vk.com

«Балалар да эшкә өйрәнә», – ди Илнур

Биектау районының Алан-Бәксәр җирлегендә яшәүчеләр дә өмәгә чыккан.

– Әниебез авыл җирлеге башлыгы булгач, безгә үз йортыбызны гына түгел, авыл эчен дә, безгә илтүче юлларны да чиста тоту кирәк. Кешеләрнең ваемсызлыгына бик аптырыйм. Нигә чүпләрен машинадан ташлап китәләрдер инде?! Кеше артыннан бер дә чүп җыясы килми. Әмма табигать кызганыч, – ди Диана Гарифуллина.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Сан

Чистарту икеайлыгы кысасында экология инспекторлары тарафыннан **3174** кагыйдә бозу теркәлгән. Аның **2356**сын бетергәннәр. **846** беркетмә төзелгән. Тиешсез урында барлыкка килгән **1805** чүплек табылган. Шуның **1384**е бетерелгән. Икеайлык башланганнан бирле **206,2** мең кубометр каты көнкүреш калдыклары чыгарылган, җыештыруда **288** мең кеше катнашкан.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЛАРЫ

«Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткәннәре, Бөек Ватан сугышы елларында хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин иткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге өчен «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исемен бирергә:

«Л.Я. Карпов исемендәге химия заводы» акционер җәмгыятенә;

«Кукмара киез-итек комбинаты» акционер җәмгыятенә.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнеханов
Казан, Кремль, 2023 ел, 29 апрель
№ 267

«Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру турында

2023 елда «Каравон» рус халык бәйрәмен уздыру максатларында һәм «Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, җирле үзидарә органнары һәм иҗтимагый берләшмәләр тәкъдимнәрен исәпкә алып, «Каравон» рус халык бәйрәмен 2023 елның 28 маенда Татарстан Республикасы Лаеш районының Никольское авылында уздырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны оештыруны тәэмин итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүне һәм уздыруны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә һәм оешмаларга «Каравон» рус халык бәйрәмен әзерләүдә һәм уздыруда актив катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов
Казан, Кремль, 2023 ел, 02 май
№ 270

Язучы сүзе

Исемдәмени хикмәт...

Минем үземнең исемгә бик исем китми. Әллә кемнәр әллә ниләр кыланып, хәтта үз исемнәрен үзгәртеп бетерде. Безнең авылда бер Миррев дигән кеше бар иде. Әти-әнисе мировой революция турында хыялланып, пыр тузышып ятканда ялгыш туган малай инде бу. Заманнар үзгәреп, коммунистлар партиясе юкка чыккач, исемен алыштырды. Мирсәет дип. Үзе сизгәндер инде, үзенә рәхәт булгандыр. Авыл халкы берни сизмәде. Элек тә Мөртәт дип йөриләр иде, хәзер дә шулай диләр.

Бер мәлне авылның исемен алыштырырга булдылар. Элек Кызыл Коммунар иде. Заманча түгел бит инде... И бәхәсләшәләр, и сөйләшәләр, и чәйниләр... Авылдан чыккан бер Советлар Союзы Герое, бер дөнья чемпионы, бер халык артисты бар. Шуларның исемен кушарга тырышалар. Бер генә атаклы кеше булса, бәлки, шуның исемен бирерләр иде. Ә монда өчәү! Ә безнең авыл – татар авылы. Татар кешесе, гадәттә, өченең берсен сайлап ала башласа, бишкә бүленеп, талашып китә. Монда да шулай булды. Нәтиҗәдә Тишекле дип куштылар. Чөнки авыл читендәге яланда бик тирән бер чокыр бар... Булган... Элек чокыр булган инде, хәзер бөтәшеп, тишек кенә булып калган. Шуның хөрмәтенә куштылар. Данлыклы кешеләр күп авылда, ә тишек берәү генә. Мин катнашмадым. Нәрсә дип атасаң да, шул беткән бер авыл инде. «Алтын» дип кушсаң да, ялтыраячак эше юк.

Бераздан шәһәргә күчеп килдем. И, шәһәр халкының бер эше дә юк икән. Көн-таң атса, исем алыштыру белән мәш киләләр... Безнең яндагы автобус тукталышының исемен алыштырдылар. И бәхәсләшәләр, и сөйләшәләр, и чәйниләр... Әллә кемнәрне санап чыктылар. Ахыр чиктә, «Сазлык» дип куштылар. Бик әйбәт, бик тарихи исем икән. Безнең эрага кадәр ничәнчедер миллионынчы елда бу урыннарда сазлык булган. Шуның хөрмәтенә кушканнар. Моны ачыклаган бер галимгә шул хезмәте өчен премия дә бирделәр әле. Мин катнашмадым. Нәрсә дип атасаң да, шул беткән бер тукталыш инде. Автобус килгәнен сәгатьләр буе көтәргә кирәк. Сазга батсаң да, тизрәк чыгарсың.

Аннан соң урам исемен алыштырдылар. И бәхәсләшәләр, и сөйләшәләр, и чәйниләр... «Ничек дип атыйбыз, нинди исем кушабыз?» – диләр. Гәзитләрдә бәхәс куптардылар, телевизордан «түгәрәк өстәл»ләр үткәрделәр. Әллә күпме бөек кешеләре бар икән татарның. Исемнәрен кушып бетерү өчен бер урам гына җитми. Аларга урыслар каршы төште: «Нәрсә сез гел татар исемнәрен генә кушмакчы буласыз, Россиядә яшисез бит, безнең атаклы кешеләрне дә кимсетмәгез», – диләр. Шуннан боларны безнең татар түрәләре күтәреп алды. Урыс исеме сайлый башладылар. И эзлиләр, и эзлиләр. Пушкин бар, Гагарин бар, Державин бар... Исем таба алмадылар. Безнең шәһәр урамнарына бирелмәгән бер урыс исеме дә калмаган икән. Шуннан Дуслык дип куштылар. Мин катнашмадым. Һи, исемдәмени хикмәт... Нәрсә дип атасаң да, шул беткән бер урам инде...

Әнә шул Дуслык урамындагы «Сазлык» дигән тукталыштан автобуска утырып киткән идем, караклар сумкамны чистартып чыккан. Акчам булмаганга, штраф җәһәтеннән паспортымны, документларымны алганнар. Паспортны яңадан ясатырга туры килде. Шуны алып кайтып киләм әле.

Шайтан алгыры!

Имам бит мин! И-мам! Ә монда Иван дип язганнар. И-ван!

Кире артыннан йөрсәң, тагын әллә күпме көтәргә, әллә күпме түләргә туры килер инде. Һи, исемдәмени хикмәт. Кем дип атасаң да, шул бер мин инде ул. Исем алыштырудан сумма үзгәрми, бер математик әйтмешли. Исем кайгысымыни әле монда?! Акча юк. Иртәгә кредит түлисе бар.

Марат КӘБИРОВ

Реклама

Тамашачы 27 май ТМТВ премиясен тапшыру тантанасын үз күзләре белән күрә алачак!

ТМТВ телевизион премиясенә – 8 ел!

Кызыл келәм, зәвыклы номерлар, кызыклы образлар, популяр хитлар, яраткан артистлар – берничә сәгатьлек мавыктыргыч музыкаль шоуны сез дә күрә аласыз!

Казанның үзәгендә – «Пирамида»да очрашырбыз!

Заманча, татарча, елның иң масштаблы вакыйгасына һәркем килә һәм бәйрәмнең катнашучылары булып, яраткан «йолдыз»ларының җиңүенә сөенә ала!

Чиксез музыка, ләззәт океанына бергә чумыйк!

Билетлар сатуда (https://kzn.kassir.ru/koncert/krk-piramida/premiya-tmtv_2023-05-27).

ИКЕ ЕЛ ӨЗ КӨННӘН СОҢ... КИЛӘЧӘК


vk.com

Көннәрне саный башладык. Мәгълүм булганча, Татарстан башкаласында 2024 елда «Киләчәк Уеннары» дигән халыкара турнир узачак. Виртуаль дөнья һәм чынбарлыкны берләштергән бу ярышларны игътибарсыз калдырырга ярамый, диләр. Ник дигәндә, турнир тарихта беренче булуы, тәүге тапкыр Казанда оештырылуы, яңалык булуы белән дә үзенчәлекле. Узган атна азагында Уеннарның әһәмияте турында ил күләмендә кабат искә төшерделәр.

«Сезне Казан көтә!»

Шәһәрләр көннәр саный. Узган атна шимбәсендә Мәскәүдә һәм Казанда «Киләчәк Уеннары» башлануга төгәл 300 көн калу уңаеннан кире хисапка старт бирделәр. Көннәрне һәм сәгатьләрне саный торган махсус стеланы ачу тантанасында җитәкчелек һәм... ясалма интеллект та катнашты.

Мәскәү белән Казан арасын якынайтып, «Киләчәк Уеннары» уңаеннан мөрәҗәгать белән Россия Президенты Владимир Путин да чыгыш ясады.

– Мондый вакыйганы беркем дә, беркайда да үткәрмәде әле, – диде ул. – Хәзерге заман кешесе, киләчәк кешесе – физик һәм интеллектуаль яктан үсеш алган, камил кеше ул. «Киләчәк Уеннары» бу хакыйкатьне ачарга мөмкинлек бирәчәк. Мондый ярышларның нәкъ менә Россиядә барлыкка килүе, популярлык яулавы белән горурланабыз. Катнашучыларны Россиянең иң үзенчәлекле төбәкләренең берсе – Татарстан башкаласы, дәрәҗәле халыкара форумнар үткәрү тәҗрибәсе булган матур, борынгы, кунакчыл Казан көтә.

Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко сүзләренчә, Уеннарга карата кызыксыну зур. «100дән артык ил катнашыр дип фаразлыйбыз. Дулкынлану да бар, җаваплылык та зур. Әмма без моңа кадәр дә бик күп ярышлар үткәрдек, тагын бер кат бөтен дөньяны шаккатырырга тырышачакбыз», – диде ул.

Аның сүзләрен Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та куәтләде. «Республикабызга, Казанга күрсәтелгән ышанычыгыз өчен рәхмәт. Тәҗрибәбез, теләгебез бар. Бу тәүге Уеннарны истә калырлык итеп үткәрәчәкбез!» – дип ышандырды Рәис.

Нәрсә? Кайда? Ничек?

Татарстан башкаласында узачак әлеге чара турында әле күп сөйләнер, күп язылыр. Шулай да төп мәгълүматны белеп тору зыян итмәс.

Билгеле булганча, Казанның әлеге ярышларны оештыру хокукына ия булуы турында 2022 елның 16 июнендә Санкт-Петербург халыкара икътисадый форумында игълан ителде. Уеннарны үткәрү хокукы өчен Россиянең тагын дүрт шәһәре – Санкт-Петербург, Мәскәү, Калуга һәм Сочи көрәште.

«Киләчәк Уеннары» – спорт, фән, технология, спортның классик төрләрен һәм цифрлаштыруны берләштергән халыкара ярыш. Спортчыларның физик мөмкинлекләре дә, виртуаль дөньядагы сәләтләре дә сыналачак. Мисал өчен, башта катнашучы егет-кызлар хоккейны кулларына джойстик тотып, экранга төбәлеп уйнаса, соңрак ярыш чын бозга күчәчәк. Турнир дисциплиналары исемлегендә булган башка ярышларга карата да шул ук таләп. «Иңиң»нәр киләсе елның 23 февраленнән 3 мартына кадәр көч сынашачак.

Уеннар «Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә оештырылачак. Моннан тыш яңа IT парк, Иннополис шәһәре мөмкинлекләре дә җәлеп ителәчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

САН

- Казан – турнирларны үткәрү хокукына ия булган беренче шәһәр.
- Ярышлар 9 көн дәвам итәчәк.
- Барлыгы 16 дисциплинада ярышлар көтелә.
- Приз фонды – 25 млн доллар.
- Уеннарда катнашуын 50дән артык ил раслаган.
- 2 меңнән артык катнашучы килер дип көтелә.



Спортчылар фикере

Илья АВЕРБУХ, фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы:

– Минем уйлавымча, бу – искиткеч проект, дөрес юнәлештәге хәрәкәт. Россия, һәрвакыттагыча, күп нәрсәләрдән юл ярып баручы. Барысы да югары дәрәҗәдә узачагына ышанам. Казан мондый чараларны ничек үткәрәсен белә һәм моны күп тапкыр дәлилләгән шәһәр дә бит ул. Катнашучыларга бераз көнләшеп тә карыйм хәтта. Мондый уеннарда катнашу – киләчәккә сикерү ул. Мин футболда көч сынашып карар идем. Виртуаль уеннарны да, кырдагысын да яратам, әмма минем уен дәрәҗәсе замана балаларыныкы кебек түгел инде. Улым да виртуаль футболны үз итә. Аның өчен дә бу Уеннар мотивация булыр иде.

Светлана РОМАШИНА, синхрон йөзү буенча җиде тапкыр Олимпия чемпионы:

– Бу – ярышларның яңа, кызыклы форматы. Фиджитал-спорт – яшьләрне дә, олыларны да берләштерә, элемтә ноктасы булып тора. Декабрь аенда фиджитал-хоккей ярышларын күзәттем. Чыннан да, бик кызыклы тамаша булды ул. Уеннарны күзәткәндә, шунысын да уйлап куйдым: фиджитал форматны бассейнга ничек күчерергә икән? «Киләчәк Уеннары» – безнең киләчәк ул.

Данис ЗАРИПОВ, «Ак барс» хоккей клубының экс-капитаны, хоккейчы:

– «Киләчәк Уеннары»на мөнәсәбәтем уңай. Тәкъдим итсәләр, фиджитал-ярышларда катнашып карар идем. Минем өчен, әлбәттә, бу – яңа формат, спорт дөньясындагы яңа проект. Һәм бу – кызыклы проект! Биредә чынбарлыктагы мөмкинлекләрең дә сынала. Яшермим: виртуаль уеннардагы уңышларым белән әллә ни мактана алмыйм. Спортның чынбарлыктагы һәм виртуаль дөньядагы төрләрен берләштерүгә начар караштa түгелмен. Яшьләрнең күбесе андый уеннарда катнаша. Киберспортның киләчәге бар. «Киләчәк Уеннары»нда иң элек хоккей ярышын карарга телим.

БЕР АДЫМ КАЛГАЧ...

Спорт

Зиннәтулла Билалетдинов Казанда каламы? Гагарин Кубогы финалында «Ак барс» белән ЦСКА арасында 7 нче очрашу тәмамлангач, төп сорау әнә шул булды. Тәҗрибәле остаз әлегә үз фикерен әйтмәде. Сикәлтәле сезон барысының да исендә калачак.



ak-bars.ru

«Ак барс» – узган сезонда игътибарны иң нык җәлеп иткән команда, дисәк, әллә ни арттыру булмас. Казан хоккейчылары өчен «Татнефть-Арена»да гына түгел, ишегалларында да, сәүдә үзәкләрендә дә җан аттылар. Башка төбәкләрдә яшәүче татарлар һәм Татарстан белән элемтәсе булган кешеләр дә аларга җиңү теләде. Узган шимбәдә хәлиткеч очрашу бетәр-бетмәс Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Ак барс» егетләренә узган сезон өчен рәхмәт әйтте. «Сез – яхшы команда! Бөтен республика һәм аннан читтәге миллионлаган тамашачы һәр матчны кызыксынып күзәтте һәм сезнең өчен җан атты. Исәпнең нинди булуына да карамастан, сез – безнең өчен барыбер чемпионнар! Зиннәтулла Билалетдиновка аерым рәхмәт! Ул безнең 17 нче санлы легенда! Кыска гына вакыт эчендә команданы лидерлар сафына кайтарды. Үзе әйткәнчә, «намуслы хезмәт кенә» «Ак барс»ны финалга китереп җиткерде», – дип язды Рөстәм Миңнеханов телеграм-каналында.

«Ак барс» уенчыларына – көмеш медаль, ЦСКАга Гагарин Кубогы тапшырылып, бер сәгать узгач, Казан клубы уенчыларның җиңелү ачысын ничек кичергәнен күрсәтте. Видеоязмадан күренгәнчә, команданың хәлен белергә «Ак барс» президенты Наил Маганов кына түгел, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә кергән. Зиннәтулла Билалетдинов аны команданың иң тугры җанатары дип атый. Дөрес, сөендерә алмадылар. «Кызганыч, булдыра алмадык. Җиңүгә бик тә якын идек. Аз гына җитмәде. Мин сезгә әйттем: бу адым иң катлаулысы булачак. Үзебезне бугазыбыздан кысып тотарга иде. Шундый итеп кысарга... – ди Билалетдинов һәм нәрсә эшләргә кирәклеген күрсәтә. – Яхшысы да күп булды. Миңа калса, бу җиңү лаеклы булачак иде. Димәк, төзәтәсе әйберләр бар әле. Тагын бер кат рәхмәт. Хәзер инде ял итегез».

«Төзәтәсе әйберләр» булгач, Зиннәтулла Билалетдинов бу эш белән үзе шөгыльләнәчәкме? Наил Маганов бу хакта баш тренерның үзеннән сорарга киңәш итте. Клубның генераль менеджеры Марат Вәлиуллин да шуннан артыгын әйтмәде. Журналистлар сорау биргәч, остаз үзе дә мәсьәләгә ачыклык кертмәде. «Миңа калса, хәзер бу хакта сөйләшүнең мәгънәсе юк. Вакыт кирәк. Ә теләк миндә һәрвакыт бар. Шул исәптән, ял итү теләге дә», – диде бишенче финалның икенчесендә оттырган Билалетдинов.

«Ак барс» белән өч мәртәбә Гагарин Кубогын яулаган хоккей остасының үз вазыйфасына ничек кайтканын барыбыз да хәтерли. Башта ул «йолдыз»лардан тупланган команданың бер урында таптануын читтән генә күзәтеп торды. Олег Знарок киткәч, баш тренер булып түгел, ярдәмче вазыйфасында эшләргә ризалашты. Ахырдан исә дилбегәне үз кулына алды. Камчысын да онытмаган булып чыкты. Хоккей җанатарлары көлкесенә кала язган команда Көнчыгыш конференциясендәге ярышны беренче урында тәмамлады. Хәлиткеч финалда оттырып барганда Казан командасы рәттән ике уенда җинде һәм тамашачыга җиденче очрашуны күрү насыйп булды. Дүртенче мәртәбә Гагарин Кубогын яуларга нибары бер адым җитмәде.

«Команданы кабул итеп алганда, финалга чыгып, җиденче очрашуда гына оттырасыгызны әйтсәләр, ышаныр идегезме?» – дип сорады «Ватаным Татарстан» хәбәрчесе остаздан. «Миңа беркем дә берни дә әйтмәде. Хәлләр бик җиңел түгел иде. Безнең уеннардан канәгатьлек алдым. Финалга кадәр барып җитүебез гаҗәп түгел. Команда җиңәрлек итеп уйнады һәм җиңәргә тиеш иде. Әмма көндәш тә гади генә команда түгел. Алар да тырышты», – диде ул.

Сезон тәмам, инде киләсе ярышка әзерлек башланды. КХЛдагы командаларда үзгәрешләр башланды. Яңалыклар «Ак барс»та да булачак, әмма күп түгел. Ник дигәндә, берничә хоккейчының гына килешү вакыты чыга. Китүчеләр арасында һөҗүмчеләр Дмитрий Воронков белән Кирилл Петровны телгә алалар. Александр Радулов белән бергә уйнап, осталыгын тагын да чарлаган Воронковны океан артында көтәләр. Әйтүләренә караганда, «Ак барс» калырга үгетләсә дә, егетнең үзен НХЛда сынап карыйсы килә. «Ак барс», ЦСКА һәм «Авангард»та уйнаганда 5 мәртәбә финалга чыгып, бер тапкыр да Гагарин Кубогын кулына алып карамаган Петровның исә Минскига китәсен хәбәр иттеләр. Билгеле булганча, андагы «Динамо»га баш тренер итеп моңа кадәр Казанда эшләп киткән Дмитрий Квартальновны билгеләделәр. Һөҗүмчеләр Кирилл Панюков белән Михаил Глухов та киләсе сезонны башка командада башларга мөмкин.

НХЛда уйнап, ике мәртәбә Стэнли Кубогын яулаган Вячеслав Войнов узган сезонда «Ак барс»ның төп сакчысы булырга тиеш иде. Яхшы гына хезмәт хакы алучы хоккейчы белән ике елга яңа килешү дә төзеделәр. Әмма кыйммәтле уенчы өметләрне аклады дип әйтеп булмый.

Китү ихтималы булган уенчылар арасында сакчылар Динар Хафизуллин белән Василий Токрановны телгә алалар. Икесе дә – Татарстан егетләре. Әмма плэй-оффта чыгыш ясарлык уен күрсәтә алмадылар. Димәк, җиңү өчен яңа егетләрне чакырачаклар.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5313 данә
Гомуми тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 262

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+